РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2015 № 1557-п

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетына кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен раслау турында*

"Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы, Саба муниципаль районының башкарма комитеты нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетына гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен расларга.
2. Оештыру бүлегенә гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясарга (алга таба – анализ) яртыеллыкның соңгы аеннан соң килгән айның 15 числосына кадәр елга ике тапкыр .
3. Оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында анализ урнаштыруны яртыеллыкның соңгы аеннан соң килгән айның 10 числосына кадәр тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе М.Р.Кәримовка йөкләргә

Руководитель Р.М. Гасимов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 2015
елның 16 февралендәге 1557-п
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетына кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - район Башкарма комитеты) гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау шушы Тәртипнең 3 һәм 4 пунктлары нигезендә бирелә торган электрон документлар әйләнеше һәм мәгълүмат белешмәләре нигезендә Саба муниципаль районыБашкарма комитетының оештыру бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Саба муниципаль районы вазыйфаи затларын шәхси кабул итүгә килгән мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат гражданнарны шәхси кабул итүгә теркәүне гамәлгә ашыручы оештыру бүлеге белгечләренә бирелә.

4. Анализ үткәрелгәндә кергән, башкаларга кергәнне җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең саны, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булган очракта) турында мәгълүмат өйрәнелә.

5. Әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан яртыеллыкның соңгы аеннан соң килгән айның 10 числосына кадәр тапшырыла.

7. Бүлек җитәкчесе 2 пунктта күрсәтелгән мәгълүматны, шулай ук әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктлары нигезендә кергән мәгълүматны ике эш көне эчендә гомумиләштерә һәм анализлый.

8. Мөрәҗәгатьләрне анализлау Саба муниципаль районының рәсми сайтында яртыеллыкның соңгы аеннан соң килгән айның 15 числосына кадәр урнаштырыла.

9. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау Саба муниципаль районының рәсми сайтында ирекле файдалануда ачык мәгълүмат булып тора.